БИСМИЛЛАҺ-ИРРАХМАН-ИРРАХИМ
Әле күптән түгел генә башка айлар арасында өстен ай – Рамазан аен тәмамладык. Тәкъвалыгыбызны арттыра, калебләребезне пакъләндерә, сәламәтлегебезне ныгыта торган шушы ураза аенда һәр мөселман кешесе күркәм гамәлләр кылырга ашыкты. Шуларның берсе авылдашыбыз Азат Фәнис улы Сабиров булды. Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнарының Диния нәзарәте оештырган  “Хәйрия” фондыннан  матди бүләкләрне Яр Чаллы бүлегеннән  алып кайтуда күрсәткән ярдәме өчен аңа зур рәхмәтебезне белдерәбез. Бу бүләкләр авылдагы Аллаһы Тәгалә кешеләренә, өлкән яшьтәгеләргә, мохтаҗ кешеләргә өләшенде.
Раббыбыз Аллаһ Азат Фәнис улына мәрхәмәтен, мәгърифәтен насыйп әйләсен, изге ниятләренә ирешергә көч-куәт бирсен! Киләчәктә дә башка авылдашларыбызга үрнәк булып яшәргә язсын!

Мансур хәзрәт Гәрәев.